СОВЕТ КАРАДУВАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАРАДУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«30» июнь 2021 ел. № 26

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Карадуган авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм 2020 елның 31 июлендәге Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә «Санлы финанс активлары, санлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 259-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «санлы финанс активлары, санлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында «Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында»2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 26.12.2020 № 97-ТРЗ номерлы ТР Законы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге Советы карары:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының "Карадуган авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Карадуган авыл җирлеге Советының 2016 елның 13 апрелендәге 24 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәнең 2 пунктындагы "г" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

г) җир кишәрлеген, күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында пайларның катнашу өлеше), санлы финанс активлары, санлы валютаны сатып алу буенча алыш-бирешләр кылган акчаларны алу чыганаклары, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы соңгы өч елда хезмәткәрнең һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә, һәм алыш-бирешлр кылган акчалар алу чыганаклары турында белешмәләр.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

4. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә.

Карадуган авыл җирлеге башлыгы: Ш.В.Низамиев